КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 5 май г.Казань № 417

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет учреждениеләренең һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан ассигнованиеләр ала торган башка оешмаларның эшмәкәрлек эшчәнлеге турында» 2004 ел, 31 август, 395 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 ел, 11 ноябрь, 487 нче; 2005 ел, 18 май, 218 нче; 2005 ел, 14 июнь, 266 нчы; 2005 ел, 15 сентябрь, 451 нче; 2005 ел, 28 ноябрь, 558 нче; 2006 ел, 2 октябрь, 494 нче; 2007 ел, 20 сентябрь, 478 нче; 2007 ел, 22 ноябрь, 651 нче; 2008 ел, 16 октябрь, 753 нче; 2008 ел, 1 декабрь, 844 нче; 2009 ел, 5 июнь, 368 нче; 2009 ел, 24 июль, 516 нчы; 2009 ел, 31 декабрь, 931 нче; 2010 ел, 19 апрель, 272 нче; 2011 ел, 14 февраль, 104 нче; 2017 ел, 20 июнь, 402 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру кысаларында бюджет учреждениеләренең һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан ассигнованиеләр ала торган башка оешмаларның гражданнарга һәм юридик затларга күрсәтә торган хезмәтләре исемлегенә, 7 бүлекне төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыру турында» 2020 ел, 29 апрель, 346 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 19 декабрь, 1157 нче; 2021 ел, 1 сентябрь, 801 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 2 пунктның егерме җиденче абзацында «янгын-техник минимумы программалары буенча һәм» сүзләрен «, янгын куркынычсызлыгы чаралары һәм гигиена әзерлеге программалары» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин